**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.12.2017 Балык Бистәсе штп. № 254пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның дәүләти һәм муниципаль унитар предприятиеләр эшчәнлеге өчен контрольнең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча 2016 елның 28 гыйнварындагы ПР-19 номерлы Йөкләмәләр исемлегенең 5.1 пунктын үтәү йөзеннән һәм 2002 елның 14 ноябрендәге “Дәүләти һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында”гы 161-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясе төзергә.

2.Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясе турындагы Нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясендә карауга әзерләнү буенча сораулар исемлеген;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясе составын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Х. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2017елның 4 декабрендәге
254пи номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясе турында Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясе (алга таба – комиссия) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы хуҗалык комплексының агымдагы икътисади проблемалары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең социаль-икътисади үсеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләрен финанс ягыннан савыктыру мәсьәләләрен карау һәм чаралар күрүне тәэмин итүче даими эш итүче яраклаштыручы орган булып тора.

1.2.Комиссия үзенең эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга,Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының башка норматив-хокукый актларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясе турындагы әлеге Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) таянып эш итә.

1.3.Комиссия составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана һәм Комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе һәм Комиссия әгъзаларыннан тора.

1.4.Комиссия үзенең эшчәнлеген Комиссия рәисе раслаган план нигезендә гамәлгә ашыра.

Комиссия утырышлары зарурлык булганда үткәрелә, әмма кварталга бер мәртәбәдән дә ким түгел.

1.5.Комиссия утырышларын Комиссия рәисе яки аның йөкләмәсе буенча Комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

1.6.Комиссия утырышы аның составының яртысыннан артыгы катнашканда вәкаләтле санала.

Комиссия әгъзалары аның утырышларында алмаштыруга хокуксыз рәвештә катнашалар. Комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаган очракта

карала торган мәсьәләләр буенча ул үз фикерен алдан язмача рәвештә ирештерергә хокуклы.

1.7.Комиссия карары утырышта катнашучыларның яртысыннан артыгы яклап тавыш биргәндә кабул ителгән дип санала.

Тавышлар саны тигез булган очракта утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

1.8.Комиссия карары Комиссия рәисе, ул юкта Комиссия рәисе урынбасары һәм Комиссия сәркатибе кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

1.9.Компетенциясенә ярашлы рәвештә Комиссиянең кабул иткән карарлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләре өчен мәҗбүри һәм башка җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, милек рәвешенә бәйсез рәвештә оешмалар, предприятие һәм учреждениеләр өчен киңәш-тәкъдим итү үзенчәлегенә ия.

1.10. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати тәэмин итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территория үсеш бүлеге гамәлгә ашыра.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары

Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендәге агымдагы икътисади вәзгыять проблемаларын карау;

2)икътисадның төрле тармакларындагы хәлне тотрыкландыруга юнәлтелгән программалар, чараларны карау;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы хуҗалык комплексы тармакларында резервлар эзләп табу буенча мәсьәләләрне карау;

4) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең сарыф итүләр маддәләре буенча керем һәм чыгымнарын анализлау;

5) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең түли алмаулары һәм бурычларын түләргә хәлләреннән килмәве (бөлгенлеге) белән бәйле мәсьәләләрне карау һәм аларның финанс-икътисади хәлләрен яхшырту буенча тәкъдимнәр эшләү;

6)хезмәт хакын, пособиеләрне һәм бүтән социаль түләүләрне үзвакытында түләүне тәэмин итү буенча килештерелгән чаралар күрү;

7) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре, биналар һәм мөлкәтнең нәтиҗәле файдаланылуын анализлау.

## 3. Комиссия эшчәнлеген оештыру

3.1.Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген, Россия Федерациясенең салым һәм банк законнарын үтәвен тикшерүләр үткәрү турындагы мәсьәләләрне карый;

2)утырышларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең җитәкчеләрен чакыра;

3) Россия Федерациясенең бюджет, салым, банк законнарын бозган һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджет чараларын максатчан файдаланмаган өчен ( аларның муниципаль предприятиеләргә бирелү очрагында) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең җитәкчеләрен җаваплылыкка тарту турында компетентлы органнарга тәкъдимнәр кертә;

4) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-икътисади хәлен яхшырту буенча тәкъдимнәр кертә;

5) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренә бөлгенлек куркынычы килеп тууы һәм бөлгенлеккә илтүче хокукка каршы гамәлләре турында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, зарурлык булганда башка компетентлы органнарга хәбәр итә;

3.2.Комиссия рәисе Комиссия белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, шул исәптән:

Комиссиянең регламентын һәм эш планын раслый;

Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

Комиссия беркетмәләрен имзалый;

Комиссия утырышларын уздыру даталарын билгели;

Комиссия утырышларын үткәрү турында карар кабул итә.

3.3.Комиссия сәркатибе Комиссия каравы өчен материаллар әзерләүне, карала торган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең үзара бәйләнешен координацияләүне гамәлгә ашыра.

3.4.Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бару Комиссия сәркатибенә йөкләнә.

3.5.Комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында чакырылган кешеләргә Комиссия утырышы көненә кадәр ике эш көне алдан хәбәр ителә.

## 4. Комиссиянең хокуклары

4.1. Комиссия хокуклы::

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнарыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының башка җирле үзидарә органнарыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләреннән Комиссия эшчәнлегенә кагылган сораулар буенча мәгълүматлар (материаллар) алырга;

комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә башкарма хакимиятнең федераль органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, шулай ук оешмалардан мәгълүматлар соратып алырга;

вакытлы эшче төркемнәр төзергә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2017елның 4 декабрендәге
254пи номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясендә карауга әзерләнү буенча сораулар исемлеге**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләре өчен (алга таба – предприятие):

1.Предприятиенең исеме, аның урнашу урыны, (учреждениенең) төзелү датасы, предприятиенең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры турында мәгълүмат.

2.Максатлары, предметы, Уставы буенча эшчәнлек төрләре. Устав капиталы, катнашучыларның устав капиталындагы өлешләре.

3.Башкарылучы эшләрнең һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең исемлеге.

4.Башкарылучы эшләр һәм хезмәтләрнең тариф күләмнәре.Тарифларны килештерү яки раслау турында мәгълүмат.

5.Җир кишәрлекләрен, муниципаль милек мөлкәтен арендалау. Төзелгән шартнамәләр, аренда түләве ставкалары, аренда түләүләре торышы турында мәгълүмат. Мөлкәтне файдалану. Әйбер хокукында муниципаль унитар предприятиенеке булып торган җир кишәрлекләре, мөлкәт турында мәгълүмат.

6.Хисап чоры өчен хуҗалык эшчәнлеге йомгаклары. Алдагы елның тиң чоры белән чагыштыруда төп күрсәткечләрнең динамикасы.

7. Алдагы елның тиң чоры белән чагыштыруда предприятиенең сарыф итүләр маддәләре буенча керемнәре һәм чыгымнары, тормышка ашырылудан тыш чыгымнарны расшифровкалау. Сарыф итүләрнең үсеш сәбәбен аңлату.

8.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиесе карамагында калган табыш өлешен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына күчерү турында мәгълүмат

9. Салым салу системасы. Хисап чорында исәпләнгән һәм түләнгән салымнар суммасы турында мәгълүмат. Алдагы елның тиң чоры белән чагыштыруда салымнар һәм түләүләр төрләре буенча аерым барлык дәрәҗәдәге бюджетлар һәм бюджеттан тыш фондлар алдындагы бурыч.

10.Дебитор һәм кредит бурычы составы, аларның барлыкка килү сроклары һәм сәбәпләре. Бурычны киметү буенча чаралар.

11. Рентабельлелекне арттыру һәм зыянны киметү буенча чаралар.

12.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиесендә Коллектив шартнамәнең булуы. Предприятиенең хезмәткә түләү һәм бүләкләү турындагы нигезләмәләренең булуы. Бүләкләүнең күрсәткечләре һәм шартлары.

13.Предприятие хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү, аның дәрәҗәсе. Хезмәт хакын түләүнең тоткарлану фактлары һәм сроклары. Штат расписаниесе буенча сан, уртача исемлек саны.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2017елның 4 декабрендәге
254пи номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау буенча баланс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин Рашат Хәбриевич | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Низамов Данис Әнәсович | инфраструктура үсеше буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Гатиятов Дилүс Харисович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территория үсеш бүлеге башлыгы, комиссия сәркатибе |
| Комиссии әгъзалары: | |
| Рәшитов Роберт Рәфыйкович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килештерү буенча) |
| Ногманова Илсия Мәликовна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килештерү буенча) |
| Бәдретдинов Азат Илдусович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе (килештерү буенча) |
| Елисеева Алсу Марсельевна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы |
| Җамалиев Рөстәм Рәсимович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлек башлыгы (килештерү буенча) |
| Хәсәнов Рәүф Ногманович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак- |

| | |
|---|---|
| | коммуналь хуҗалык бүлеге  башлыгы |
| Шәйдуллина<br>Гөлназ Рәйхановна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты территория үсеш бүлегенең әйдәүче белгече |
| Сәйфуллина<br>Лилия Жәүдәтовна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының әйдәүче белгече (килештерү буенча) |
| Җаббаров<br>Марат Марсилович | Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы Казначылык департаментының Балык Бистәсе муниципаль районындагы территория бүлеге җитәкчесе (килештерү буенча) |
| Вәлиева<br>Минзия Госмановна | Россия Пенсия Фондының Балык Бистәсе районындагы идарәсе башлыгы (килештерү буенча) |
| Гарифуллина<br>Рәсимә<br>Әхмәтзакировна | Балык Бистәсе районы  “Халыкның мәшгульлек үзәге” дәүләт казна учреждениесе директоры (килештерү буенча) |
| Билалова<br>Мәгъмүрә Кыямовна | әйдәүче белгеч – Казан ш. (Балык Бистәсе штп.) дәүләт статистика бүлеге  эксперты  (килештерү буенча) |
| Сираева<br>Нурисә Рашатовна | Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фондының Балык Бистәсендәге региональ бүлекчәсе – Дәүләт учреждениесенең №8 филиалы  баш белгече  (килештерү буенча) |
| Мәгыйзов<br>Марс Венерович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге  Башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча) |